Туган тел һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” Бөтенроссия мастер-класс бәйгесенә тәкъдим итү кәгазе.

Токранова Эльвира Ильяс кызы 1977нче елның 11 нче ноябрендә Балык Бистәсе районы Олы Әшнәк авылында туган. Югары белемле, КДПУның татар теле һәм әдәбияты бүлеген “Татар теле, әдәбияты, Татарстан тарихы укытучысы” белгечлеге буенча 1998 елда тәмамлаган.

| № | Эш урыны | вазифа | вакыты |
|---|---|---|---|
| 1 | Казан шәһәре Авиатөзелеш районы МГБУ “26нчы лицей” | татар теле, әдәбияты, Татарстан тарихы укытучысы, укыту эшләре буенча директор урынбасары | 24.08.1998-27.08.2005 |
| 2 | Балык Бистәсе районы “Казаклар Чаллысы урта гомуми белем бирү мәктәбе”МГБУ | татар теле, әдәбияты укытучысы | 29.08.2005-29.08.2013 |
| 3 | Балык Бистәсе районы “Балык Бистәсе 2нче гомуми белем бирү мәктәбе” МБГБУ | татар теле, әдәбияты укытучысы | 01. 09.2013-; |

<u>Квалификация категориясе:</u> югары

<u>Эш стажы</u>: 18 ел

<u>Эш шартлары</u>: 2016-2017нче елда- татар теле, татар әдәбияты дәресләре, 3б (татар төркеме), 3в (татар сыйныфы), 9б (рус төркеме), 2б( рус төркеме), 1и(рус төркеме).

Токранова Э.И. педагогик хезмәт нәтиҗәләре өчен түбәндәге мактау кәгазьләре белән бүләкләнде:

- ТР Мәгариф Министрлыгы Мактау Грамотасы Боерык №57-н 13.05.2003;
- Татар теленнән олимпиада җиңүчесе әзерләгән өчен Казан шәһәренең Мәгариф идарәсенең Мактау хаты, 2005;
- ТР М Мактау Грамотасы (Боерык №180-н 08.07.2010);
- " Татар әдәбиятыннан республика олимпиадасы призерын әзерләгән өчен" ТР Мәгариф Министрлыгы Мактау Грамотасы 2011;
- “Ел укытучысы- 2010” бәйгесе җиңүчесенә Балык Бистәсе муниципаль районы Мактау грамотасы (Боерык №495, 24.09.2010);
- Балык Бистәсе муниципаль районы администрациясенең Мактау кәгазе,2010ел;
-" Татар әдәбиятыннан республика олимпиадасы призерын әзерләгән өчен" ТР Мәгариф һәм Фән Министрлыгы Мактау Грамотасы 2014;
-“Ел укытучысы- 2015” бәйгесе җиңүчесенә Балык Бистәсе муниципаль районы Мактау грамотасы (Приказ №81 18.02.2015);

- «Ак калфак» татар хатын —кызлары оешмасы Балык Бистәсе муниципаль районы бүлегенең мактау хаты , 2015.
- Балык Бистәсе муниципаль районы администрациясенең Мактау кәгазе, 2016 ел;

2014нче елда, лаеклы рәвештә, “Безнең иң яхшы укытучыбыз” республика грантына ия булды.

Токранова Эльвира Ильяс кызы үзенең педагогик эшчәнлегендә алдынгы технологияләргә таянып эшли, эш нәтиҗәләре белән семинарларда, конференцияләрдә катнаша, укытучыларның профессиональ бәйгеләрендә осталыгын күрсәтә. Ул “Ел укытучысы” Бөтенроссия бәйгесенең муниципаль этабында 2010, 2015нче елларда җиңүче булды, 2011нче елда республика бәйгесендә лаеклы чыгыш ясады. Шулай ук район күләмендә иҗади эшләр һәм олимпиада комиссияләре составында эшли. 2016нчы елда БРТ тикшерү буенча Республика комиссиясендә эшли.

Укучыларын фәнни һәм иҗади эшкә кызыксындыра белә, республика күләмендә чаралар: олимпиада, фәнни-гамәли конференцияләрдә алар уңышлы чыгыш ясыйлар.

Укытучы мәктәп базасында алып барыла торган инновацион мәйданчык эшчәнлеге төркеме составында эш алып бара. Эш тәҗрибәсе үрнәкләрен республика һәм регионара конференцияләр эшчәнлеген яктырткан җыентыкларда күрергә була.

“Балык Бистәсе 2нче номерлы гомуми урта белем бирү мәктәбе” МГББУ укытучысы Токранова Эльвира Ильяс кызының уңай эш тәҗрибәсе республика күләмендә уртаклашуга лаек дип табыла, Бөтенроссия Туган тел һәм әдәбияты укытучыларының “Туган тел” мастер-класс бәйгесендә катнашырга тәкъдим ителә.

Балык Бистәсе муниципаль районы
Башкарма комитетының “Мәгариф
бүлеге муниципаль казна
учреждениесы” башлыгы:

И.М. Садыйков